220

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I. "Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 2 маддәдә "һәм СССРның" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2. 4 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Югары Советы Мандат комиссиясен; Закон чыгару мәсьәләләре буенча комиссияне; Законлылык, хокук тәртибе, кеше хокуклары һәм өстенлекләр буенча комиссияне; План һәм бюджет-финанс комиссиясен, шулай ук дәүләт, хуҗалык һәм җәмгыяви-мәдәни төзелешнең башка мәсьәләләре буенча даими комиссияләрен төзи".

3. 6 маддәдә "Татарстан Республикасы Министрлар Советы Рәисе" дигән сүзләрне "Татарстан Республикасы Премьер-министры" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

4. 10 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару мәсьәләләре буенча комиссиясенә түбәндәгеләр йөкләнә:

1/ Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Президиумы кушуы буенча яисә үз инициативасы белән Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советының башка актлары

проектларын әзерләүне, законнар чыгаруны камилләштерү белән бәйле башка мәсьәләләрне карау, бу мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү;

2/ комиссиягә тапшырылган Татарстан Республикасының законнары, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумының башка актлары проектларын карау һәм алар буенча тиешле нәтиҗәләр әзерләү;

3/ башка даими комиссияләрнең үтенече буенча Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советының һәм аның Президиумының тиешле комиссияләре тарафыннан әзерләнә торган башка актлары проектларын эшләүдә катнашу;

4/ Татарстан Республикасы законнарын системага салу мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү;

5/ гамәлдәге законнарны бозу ачылган очракта комиссия материалларны тикшерү һәм тиешле чаралар кабул итү өчен прокуратура органнарына яисә башка органнарга һәм оешмаларга җибәрә".

5. Законны түбәндәге эчтәлектәге яңа 10[I] маддә белән тулыландырырга:

"Татарстан Республикасы Югары Советының Законлылык, хокук тәртибе, кеше хокуклары һәм өстенлекләр буенча комиссиясенә түбәндәгеләр йөкләнә:

1/ Татарстан Республикасы Югары Советы, аның Президиумы кушуы буенча яисә үз инициативасы белән Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумының законлылыкны, хокук тәртибен ныгыту, кеше хокукларын яклау һәм өстенлекләр белән бәйле мәсьәләләр буенча башка актлары проектларын әзерләү;

2/ комиссиягә тапшырылган Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумының башка актлары проектларын карау һәм алар буенча тиешле нәтиҗәләр әзерләү;

3/ Татарстан Республикасы Югары Советына сайлау, билгеләү

яки раслау өчен тәкъдим ителүче Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Регламенты тарафыннан билгеләнгән кандидатураларны алдан тикшерү һәм әлеге кандидатуралар буенча нәтиҗәләр бирү;

4/ законлылыкны үтәү, гражданнарның хокукларын һәм закон нигезендә саклана торган мәнфәгатьләрен яклау, закон чыгаруны камилләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның, предприятиеләрнең һәм оешмаларның, шулай ук җирле дәүләт органнарының һәм оешмаларының белдерүләрен һәм нотыкларын тыңлау һәм алар буенча тиешле карарлар кабул итү;

5/ законлылыкны бозу ачылган очракта комиссия материалларны тикшерү һәм тиешле чаралар кабул итү өчен прокуратура органнарына яисә башка органнарга һәм оешмаларга җибәрә".

6. II маддәнең I һәм 2 пунктларындагы "Советы" сүзен "кабинеты" сүзе белән алмаштырырга.

7. I8 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты составына урындагы кешеләрне билгеләү һәм сайлау, Татарстан Республикасы Югары суды һәм Югары арбитраж суды судьяларын, район /шәһәр/ халык судларының халык судьяларын сайлау һәм район /шәһәр/ халык судларының рәисләрен раслау Татарстан Республикасы Югары Советының тиешле даими комиссияләре нәтиҗәләре булганда үткәрелә".

8. 22 маддәнең беренче һәм икенче өлешләрендәге "Советына" дигән сүзне "кабинетына" дигән сүз белән алмаштырырга.

9. 3I маддәдә "һәм СССР" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

П. Әлеге Закон кабул итү мизгеленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.ШӘЙМИЕВ

Казан шәһәре,
I992 елның 6 июле
№ I559-XII